M. Mamin is recognized as the pioneer of scholarship on Taktash. He is the author of the first monograph written about the classic poet and innovator of Tatar literature, Hadi Taktash. Among the generation of scholars who examined the poet's life and work in dissertations and monographs within Tatar literary studies, M. Mamin holds a distinct place. However, there are significant differences between the structure and content of the monograph published in 1941 and the edition of 1952. Unfortunately, the sources for the improved and updated sections are not indicated. Furthermore, some publishers of the second edition did not always respect the "principle of author's consent" in specific cases. It is also known that Z. Iskuzhin, G. Nigmati's postgraduate student in the 1930s, wrote a monograph about Hadi Taktash. The fate of that work remains unclear. It is impossible to provide answers to all questions in a single article, so it needs further research and investigation.

**References**


1. *Ədiplərebez: biobibliografik beleshmələk: 2 tomda: 2 t.* (2009) [Our Writers: Biobibliographic Reference Book: In 2 Volumes]. 2 t. Təz. R. N. Dautov, R. F. Rakhmani. 735 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)
2. *Alar safta: Bөek Vatan sugyshynda həlak bulgan tatar sovet yazuchylarynyң əsərləre* (1961) [Among the Ranks: The Works of Tatar Soviet Writers Who Died in the Great Patriotic War]. Təz. S. Shakir. 259 p. Kazan, Tat. kit. nəshr. (In Tatar)
3. *Alar safta: Shigyr'lər, khikəyalər* (1985) [Among the Ranks: Poems, Stories]. Təz. S. Shakir. Ikenche basma. 216 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)
4. *Kaharman kaləme: shigyr'lər, khikəyalər, əsərlərdən өzeklər* (2010) [The Hero's Pen: Poems, Stories, and Excerpts from Works]. Төz. V. Nuriev, L. Safiullina; keresh sүz avt. I. Ibrahimov. 223 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)
5. Mamin, M. (1941). *Taktash poehziyase* [The Poetry of Taktash]. 172 p. Kazan, Tatgosizdat. (In Tatar)
6. Khalitov, G. M. (1980). *Poehziya derzanii* [The Poetry of Audacity]. Issledovanie. 160 p. Kazan', Tat. kn. izd-vo. (In Russian)
7. Gali, G. (1958). *Shagyir' һadi Taktash turynda* [About the Poet Hadi Taktash]. Sailanma əsərlər: Khikəyalər, ocherklar, tənkyit' məkalələre həm publitsistika. Pp. 226–269. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)
8. *Galimҗan Nig"məti: tormyshy, yazmyshy, fənni-metodik ehshchənlege* (2018) [Galimzhan Nigmati: His Life, Fate, Scientific and Methodological Work]. 251 p. Kazan, Brig. (In Tatar)
9. Salmatova, G. D. (2021). *1920–1950 ellar iҗtimagyi həm mədəni kontekstynda Shəekhzadə Babich mirasy* [The Legacy of Shehzade Babich in the Socio-Cultural Context: From the 1920s to 1950s]. Tatarica. No. 16 (1), pp. 78–102. (In Tatar)
10. Khəbetdinova, M. (2021). *Tatar ədəbiyat belemendə Zyya Iskuzh iseme* [The Name Ziya Iskuzh in Tatar Literary Studies]. Mədəni җomga. No. 1, pp. 14–15. (In Tatar)
11. Əbүs. *Yazmalar* (2007). [Our Unforgettable Mentor]. Төz. I. K. Yanbaev. Pp. 39–41. Ufa, Kitap. (In Bashkir)
12. Vəzieva, Җ. (1987). *Zur galim, ehshlekle ostaz* [The Great Scientist and Business Mentor]. Sots. Tatarstan. 26 iyun'. (In Tatar)
13. Gosman, Kh. (1997). *Onytylmas ostazybyz* [Our Unforgettable Mentor]. Kazan utlary. No. 7, pp. 169–172. (In Tatar)
14. Mamin, M. (1952). *һadi Taktash poehziyase* [The Poetry of Hadi Taktash]. 123 p. Kazan, Tatgosizdat. (In Tatar)
15. Yuziev, N. (1998). *Ədəbiyat chyganaklary beleme (Ədəbi mirasny җyinaunyң, өirənүneң teoretik həm gaməli məs'ələləre)* [Knowledge of Literary Sources (theoretical and practical issues of collecting and studying our literary heritage)]. 175 p. Kazan, Fiker. (In Tatar)

# Һ. ТАКТАШ ТУРЫНДА БЕРЕНЧЕ МОНОГРАФИЯ АВТОРЫ (М. МАМИННЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН)

**Таһир Шәмсегали улы Гыйлаҗев,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 йорт,
tgilazov@bk.ru

Әдәби һәм фәнни эшчәнлек белән 1930 елларда актив шөгыльләнә башлаган М. Мамин, ил азатлыгын саклау максаты белән, Бөек Ватан сугышына китә. Иҗат планнары зур булып та, гомерләре вакытсыз өзелеп калган дистәләгән татар язучылары һәм журналистлары арасында М. Маминның исеме дә бар.

М. Мамин 1905 елда хәзерге Мордва Республикасы Зубов Аланы районы Горинка авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. 1918 елга кадәр авыл мәктәбендә, аннан соң Пенза шәһәрендәге укытучылар әзерләү курсларында укый. 1921 елгы ачлык чорында яңадан авылына кайтып, берникадәр вакыт авыл хуҗалыгы эшләре белән шөгыльләнә. 1924–1930 елларда авыл мәктәбендә укытучы булып эшли. Сәләтле һәм белем алуга омтылышы зур булган М. Мамин 1930 елда Казанга килеп, Көнчыгыш педагогия институтына укырга керә. «Студент елларында көндәлек матбугатта әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм рецензияләре белән катнаша башлый. 1936 елда Казан педагогия институтының аспирантурасын тәмамлаганнан соң, М. Мамин шунда әдәбият укыта. Ватан сугышы башлану белән, М. Мамин фронтка китә һәм ике ел буе алгы сызыкта фашистларга каршы сугыша. 1943 елның августында Воронеж шәһәре тирәсендә барган сугышларның берсендә өлкән лейтенант М. Мамин каты яралана һәм, шул ярадан савыга алмыйча, госпитальдә вафат була. Ул Воронеж өлкәсендәге район үзәге Воробьевка авылы зиратына күмелә. М. Мамин татар әдәбияты тарихында, нигездә, үзенең «Һади Такташ поэзиясе» исемле хезмәте белән билгеле» [1, б. 44].

М. Маминның тормыш юлы һәм иҗат биографиясе хакында мәгълүмат бик аз. 1961 елда җиңүнең 25 еллыгына Татарстан китап нәшриятында Бөек Ватан сугышында һәлак булган татар совет язучыларының әсәрләрен туплаган «Алар сафта» дигән китап дөнья күрә [2]. С. Шакир төзегән бу җыентыкта авторлар хакында белешмәләр дә бирелә. Алар арасында М. Мамин исеме һәм иҗатыннан бер үрнәк бар. Ул, зур үзгәрешләр кертелмичә, берничә язучының исеме өстәлеп, кайбер шагыйрьләрнең әсәрләре төшереп калдырылып, 1985 елда кабат басыла [3]. Һәм, ниһаять, Бөек Җиңүнең 65 еллыгын каршыларга йөргән көннәрдә Язучылар Берлеге идарәсендә яу кырында һәлак булган язучылар турында китап чыгару мәсьәләсе көн тәртибенә куела. С. Шакир төзегән җыентыкка нигезләнеп, хәзерге көн ихтыяҗын да, укучыларның да эстетик зәвыгын истә тотып, И. Ибраһимовның «Иң дәһшәтле утка керәмен» исемле кереш сүзе белән, 2010 елда «Каһарман каләме» дигән китап дөнья күрә. Китапның эчтәлеге алдагылары белән чагыштырганда баеган. Әмма аларда М. Маминга караган мәгълүматлар кабатлана. Шулай да соңгы китапны төзүчеләр В. Нуриев белән Л. Сафиуллина беренче ике китаптагы галимнең монографиясеннән алынган «Һ. Такташ поэзиясендә совет патриотизмы» дигән өзек урынына «Һади Такташ поэзиясе» исеме астында бүгенге көн таләпләренә ныграк җавап бирә торган «Такташ поэзиясендә пейзаж» дигән бүлекчәне урнаштыралар [4, б. 87–89].

М. Маминның фәнни эшчәнлеге «Һ. Такташ поэзиясе» дигән монография [5] белән генә чикләнми. 1961 елда дөнья күргән «Алар сафта» китабын төзүче С. Шакир хезмәткә язылган кереш мәкаләсендә М. Маминның, фронтка киткән Д. Фәтхи, К. Басыйров, М. Вәдүт, М. Әблиев, Х. Рахман, М. Гатау, Ш. Гәрәй, Ә. Камал, М. Мостафин, Х. Кавилар белән беррәттән, мөстәкыйль җыентыклар чыгаруын билгели [2, б. 3]. Ә инде 1985 елдагы басмасында төзүче кереш мәкаләдә «әдәби тәнкыйть мәкаләләре белән күтәрелеп килүче Мөхәммәтша Мамин» дип яза [3, б. 4]. Димәк, М. Маминның дистәләгән тәнкыйди һәм публицистик язмалары матбугат битләрендә чәчелеп ята һәм аның тормыш биографиясен дә тулыландыру мөмкинлеге бар. Эзләнүләр алып барып,

аларны туплау һәм бастырып чыгару киләчәк эше булып кала.

Алда әйтелгәнчә, М. Мамин Көнчыгыш педагогия институтын тәмамлаганнан соң, татар әдәбияты кафедрасы каршындагы аспиранурага керә. Күренекле әдәбият галиме, профессор Г. Нигъмәти җитәкчелегендә новатор шагыйрь Һ. Такташ иҗаты буенча фәнни хезмәт язуга алына. 1920–1930 елларда үзенчәлекле каләм иясе Һ. Такташ әдәби-гыйльми һәм тәнкыйди фикернең игътибары үзәгендә була. Г. Халит Такташ иҗатына багышланган «Поэзия дерзаний» (1980) исемле саллы монографик хезмәтендә Г. Гали, Г. Нигъмәти, Ш. Маннурларның очерклары, ә 1940–1950 елларда М. Маминның «Һади Такташ поэзиясе» (1941, 1952), Х. Хәйринең «Һади Такташ» (1949), Х. Госманның «Такташ поэзиясе» (1953) монографик эзләнүләре басылып чыгуын яза [6, б. 3]. Мәсәлән, М. Маминның замандашы Г. Гали шагыйрь әсәрләренең 1931, 1936 еллардагы басмаларына «Шагыйрь Һади Такташ турында» дигән күләмле монографик мәкалә шәкелендәге «Сүз башы»н урнаштыра [7].

Г. Нигъмәтинең үзен дә үзенчәлекле классик шагыйрьнең рухи мирасы кызыксындыра: «Г. Нигъмәти 1932 елда Такташ турында бик күләмле мәкалә язып бастырып чыгарган (моннан алдарак та ул вакытлы матбугатта Такташ иҗаты буенча бер серия мәкаләләр язып бастырган була); үзенең эчтәлеге, композицион төзелеше, шагыйрьнең тормыш юлын һәм иҗат юлын бер эзгә салып тикшерүе ягыннан Һ. Такташ турында язылырга тиешле монографик хезмәткә бер омтылып карау дип бәяләнергә хаклы ул һәм, мәгълүм булганча, соңрак Г. Нигъмәтинең элекке аспирантлары, яшь галимнәр М. Мамин, тагын бераз соңрак Х. Госман шул материалларны системалаштырып, тирәнәйтеп, тулыландырып, Һ. Такташ иҗаты турында монография бастыралар. Х. Госман шул нигездә кандидатлык диссертациясен яклый», – дип яза әдәбият галиме Э. Галиева [8, б. 188]. «Әдәбият мәйданында» (1925) монографиясендә әдәби методларның (реализм, романтизм, символизм, футуризм, имажинизм) типологик характеристикасын биргәндә дә, классик һәм яшь язучыларга, аеруча Һ. Такташ шигъриятенә еш мөрәҗәгать итә.

Шунысы кызыклы: нәкъ шушы елларда Һ. Такташ рухи мирасы буенча З. Искужин да гыйльми хезмәт әзерли. Искужин Зәбих Габделгазим улы 1911 елның 3 гыйнварында Башкортстанның хәзерге Зилаер районының Мәкъсут авылында күп балалы гаиләдә туа. 1926–1929 елларда Кәрвансарайда, Башкорт педагогия техникумында белем ала. 1929 елның 30 сентябреннән Казанның Көнчыгыш педагогия институты студенты булып китә һәм аны 1931 елда уңышлы тәмамлый. 1932 елның көзеннән 1935 елның язына кадәр аспирантурада укый [9, б. 92–93]. Әдәбият галиме М. Хәбетдинова Н. Исәнбәт архивында сакланган кульъязмадан түбәндәге өзекне китерә: «З. Искуж (1910– 1936) – шагыйрь һәм тәнкыйтче. Башкортстанда элекке Сабир волосте, Мәкъсут авылында туган. Гыйлемгә дәртле һәм үзенә гыйлем җитмәүгә һәрвакытта борчылучы бу талантлы язучы һәм курайчы башкорт егете, көтүчелектән күтәрелеп, укуга бирелә. Казанга килеп, Пединститутта татар тел-әдәбият факультетын һәм аспирантура тәмамлый. Тәнкыйть мәкаләләре яза, Бабич, Гафурилар турында материаллар җыя. Такташ иҗатына зур хезмәт әзерли һәм шул елда, 26 яшендә авырып, Казанда үлә» [10, б. 60]. Бу З. Искуж хезмәтенең аерым бүлекләре Уфа шәһәренең вакытлы матбугаты битләрендә басылып та чыга. Уфа якларында туып-үскән фәнгә сәләтле З. Искужинның да гыйльми җитәкчесе Г. Нигъмәти була. Бу факт М. Хәбетдинова язмасында тагын бер кат раслана: «З. Искуж – Галимҗан Нигъмәти аспиранты булуын истә тотып, мин әдәбият галиме Йолдыз Нигъмәтуллинага шалтыраттым. Йолдыз апа әнисенең хатирәләренә таянып: «З. Искуж әтинең шәкертләренең иң сәләтлесе иде» – дип җавап бирде» [10, б. 61]. Бу хакта аерым фактлар З. Искужны турыдан-туры күреп белгән кешеләрнең истәлек-хатирәләрендә дә саклана. З. Искужның Көнчыгыш Педагогия институтында укытуы, күренекле татар шагыйре Һ. Такташ иҗаты белән кызыксынуы һәм аның хезмәтләренең Татарстан Республикасы журналларында басылып чыгуы хәбәр ителә. Яшь галим замандашларыннан Әбүснең истәлек-хатирәләрендә болай искә алына: «Искужин Зәбих белән икенче мәртәбә якыннан, бик якыннан очрашуым Казанда булды. Ул анда Бабич, Такташ һәм Тукай турында язган тирән гыйльми хезмәтләрен төгәлләп, “Шимал йолдызлары” дигән бер китап чыгарырга җыенып ята иде. Бабич турында язган әйберен миңа тәнкыйтькә китерде. Бик яраттым» [11, б. 39–41].

Алда әйтелгәнчә, Көнчыгыш педагогия институтын бетергән яшь белгеч М. Маминны Г. Нигъмәти җитәкләгән татар әдәбияты кафедрасы каршындагы аспирантурага калдыралар. Аның фәнни җитәкчесе итеп, әдәбият фәнен, язучылар иҗатын тикшерүнең яңа иҗтимагый-социаль һәм мәдәни шартларда яңа методологиясен эшләп, үз фәнни мәктәбенә нигез салган профессор Г. Нигъмәти билгеләнә. Фәнни эшкә сәләтле булачак галим алдына фәнни җитәкчесе новатор шагыйрь Һади Такташ тормыш юлын һәм поэзиясен өйрәнеп, кандидатлык диссертациясен язу максатын куя. Димәк, 1930 елларда Г. Нигъмәти фәнни җитәкчелегендә язылган кандидатлык диссертациясе нигезендә Һ. Такташ иҗатына багышланган ике монографик хезмәт эшләнә. Бу, бердән, Һ Такташ иҗатының масштаблылыгы, зурлыгы, әдәби-фәлсәфи тирәнлеге турында, икенчедән исә, Г. Нигъмәтинең шагыйрь психологиясен, иҗат лабораториясен тирән һәм нечкә аңлавы, Такташ рухи мирасының катлаулы, киңкырлы, өйрәнү мөмкинлекләренең зурлыгын алдан күрә алу сәләте турында да сөйли.

Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Г. Нигъмәти 1929–1937 елларда Көнчыгыш педагогия институтында эшли. Ул – биредә милли татар бүлеген оештыручыларның берсе. Студентларга әдәбият белеме, әдәбият теориясе, XX гасыр башы, совет әдәбияты курсларыннан лекцияләр укый, гамәли дәресләр алып бара. Институтта эшләү дәверендә ул педагог буларак таныла, доцент, профессор дәрәҗәләренә күтәрелә. Бу югары уку йортының татар теле һәм әдәбияты кафедрасында ул вакытта Г. Нигъмәти белән бергә Г. Сәгъди, Г. Рәхим, Г. Гобәйдуллин, Ж. Вәлиди, Г. Шәрәф, Г. Алпаров, С. Атнагулов, С. Бикбулатов, Х. Бәдигый, М. Фазлуллин, М. Корбангалиев кебек тел-әдәбият галимнәре эшли. «Галимҗан ага җитәкчелек иткәндә педагогия институтының әдәбият кафедрасы гыйльми бер мәркәз иде, – дип искә ала Җамал Вәзиева. – Яше-карты аның тирәсенә җыйналды, аның янында тупланды. Чуваш язучысы Хузангай да, рус язучысы Зернит та аңа киңәшкә килде, хөрмәт иттеләр. Институтта тарих белгече профессор Сингалевич та, дөнья әдәбияты белгече профессор Линсцер да, рус әдәбияты доцентлары Потоцкий һәм Подъячевлар да аның фәнни карашлары белән хисаплаштылар. Чөнки ул әдәбият-сәнгатьнең иң авыр йөген тартучы интернационалист галим булды. Көнен-төнгә авыштырып намус белән эшләде. Гадел, тыйнак тормыш белән яшәде. Бөтен гомерен, барлык көчен иленә, халкына багышлады» [12].

Г. Нигъмәти тирән белемле, дөнья әдәбиятларыннан киң мәгълүматлы, теоретик әзерлекле, киң эрудицияле, югары методик осталыкка ия шәхес була. «Укытучыбыз күңелләрдә зур галим, гаять абруйлы педагог булып калды, – дип язды профессор Хатип Госман. – Ул үзенең эрудициясе белән безгә үрнәк булды. Ул татар һәм рус әдәбиятын, көнчыгыш һәм көнбатышның классик әдәбиятларын тирәнтен белә. Нинди дә булса әдәби-эстетик проблеманы яктырта башласа, син һич уйламаганда, ул бу әдәбиятларның берәрсеннән сәнгать көче үтә дә балкып торган берәр деталь китерә. Бу деталь, аның фикере белән ялганып, синең күңелеңә дә, зиһенеңә дә берьюлы тирән тәэсир ясый, бөтен рухи хәрәкәтеңне нурландырып ала [13].

Милли бүлектә уку-укыту процессын оештыру, аны фәнни кадрлар белән тәэмин итү, укыту планнарын һәм программаларын эшләү, дәреслекләр язу, аспирантлар әзерләү кебек эшләрне Г. Нигъмәти алып бара. Нигъмәти фән орлыкларын үзенең хезмәтләрендә генә түгел, укучыларына да салды, фәннең һәрвакыт үсеш хәрәкәтен, үсеш перспективасын күз алдында тотып яши. Туган халкының рухи мәдәнияте, әдәбиятының, сәнгатенең язмышы, киләчәге турында җитди кайгыртучы, ерактан, тирәннән алып уйлый белә торган киңкырлы шәхес була. Г. Нигъмәти фәнни мәктәбе традицияләрендә тәрбияләнгән һәм аның гыйльми проблемаларын тикшерүне дәвам иттергән әдәбият галиме, профессор Ф.Г. Галимуллин галимнең бу тармактагы эшчәнлеген югары бәяли: «Г.А. Нигмати оправдал возложенные на него надежды, татарское отделение при его участии заметно оживило работу по всем этим трем направлениям. Открытие им аспирантуры позволило поднять на новый уровень подготовку высококвалифицированных научно-педагогических кадров по татарской филологии. В 1933 году он становится профессором, через год был избран заведующим кафедрой татарского языка и литературы. За время своего существования аспирантура подготовила 22 литературоведа, среди них Мухаммат Гайнуллин, Хатип Гусман, Латиф Заляй, Хамит Ярми, Абдулла Сайганов, Якуб

Агишев, Ульмас Беляева, Бакер Яфаров, Мухамматша Мамин, Джамал Вазиева и другие» [8, б. 194]. Шәхес культы корбаны булып, нахакка кулга алынгач, галим сызып калдырган гыйльми юнәлешләрне, башлап калдырган актуаль темаларны, аның фәнни идеяләрен алга таба аның шәкертләре, аспирантлары дәвам итә, гамәлгә ашыра.

Г. Нигъмәти XX гасырда татар әдәбият белеменең тармакланып, киңәеп китеп үсешен, яңарышын дәвам иткән бер буын әдәбиятчылар, милли сүз сәнгатенең, татар әдәбиятын укыту методикасының күтәрелешен тәэмин иткән дистәләгән шәхесләр тәрбияли. «Профессор Г. Нигъмәти җитәкчелегендә аспирантура үткән кешеләр арасында, Х. Госман, Җ. Вәзиева, М. Маминнардан тыш, тагын Г. Халит, Х. Ярми, Я. Агишев, Г. Кашшаф, М. Гайнуллин, Б. Гыйззәт, Ш. Абилов, Т. Корбанов кебек мөхтәрәм галимнәребез бар. Г. Толымбай, З. Искужин, С. Байков, А. Кудашев, Л. Җәләй, В. Хангильдин, Х. Хисмәтуллин, Б. Яфаров, Р. Хәкимова, Р. Шакирова кебек күренекле галим-филологларыбыз да Г. Нигъмәтинең фәнни мәктәбендә чыныгу алган, методик-методологик тәүге күнегүләрне аннан өйрәнгән. Г. Нигъмәтинең фәнни-теоретик, практик казанында кайнаган талантлы әдәбият тәнкыйтьчеләрен, язучыларның исемлеген тагын да санарга булыр иде әле. Танылган язучылар, шагыйрьләр С. Хәким, А. Алиш, Г. Гобәй, Ш. Маннур, А. Әхмәт, И. Туктар, И. Сәлахов, С. Урайский һ. б., атказанган укытучылар С. Вәгыйзов, Р. Вәлитова, Б. Хәлилов һ. б. – Нигъмәти шәкертләре» [8, б. 188-189].

Татар әдәбият белемендә дөнья, аеруча Европа-Рус әдәбият белеме казанышларын милли нәзари фикере үзенчәлекләре белән синтезлап, фәнни мәктәп булдыруы һәм шушы мәктәп казанышларында югары квалификацияле белгечләре әзерләве Г. Нигъмәтинең иң югары бәяләнергә тиешле мирасы булып тора. «Димәк, чор фәнни фикеренең 1920–1930 еллар уртасы татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе буларак формалашуында, аның саллы монографияләре, әдәбият теориясенең һәм әдәби-тарихи барышның мөһим мәсьәләләрен яктырткан мәкаләләре хәлиткеч роль уйный» [8, б. 5].

М. Маминның әле төзәтүләр һәм камилләштерү мөмкинлекләре булган диссертациясе карама хәлендә кала. Яшь галимнең Һ. Такташка багышланган хезмәте 1941 елда «Һ. Такташ поэзиясе» исеме белән аерым китап булып басылып чыга [5]. Ул, Һади Такташ иҗатын тулаем алып тикшергән беренче җитди монография буларак, әдәби җәмәгатьчелектә югары бәя ала [1, б. 44]. И. Ибраһимов «Каһарман каләме» дигән китабының сүз башында олы буын әдәбиятчыларның бер әңгәмәдә М. Мамин хезмәтен югары бәяләвен ассызыклап үтә: «Мамин исә Такташ турында саллы хезмәт язды» [4, б. 4].

Сугыштан соң 1952 елда М. Маминның «Һади Такташ поэзиясе» икенче тапкыр басыла. «Билгеле, автор үзе исән булса, бик җитди төзәтүләр ясар, бигрәк тә совет әдәбиятын өйрәнү фәненең яңа казанышлары яктылыгында, яңа фикерләр белән хезмәтне баетыр һәм тирәнәйтер иде, – дип языла монографиянең башында урнаштырылган «Редакциядән» дигән кереш сүзендә. – Редакцияләү процессында бу бурычларның һәркайсын төгәлләү мөмкин түгел. Шулай да әсәргә стилистик төзәтүләрдән башка, кайбер коррективалар кертергә кирәкле табылды. Авторның Такташны өйрәнүдәге кайбер искергән карашлары төшереп калдырылды» [14, б. 2].

Әмма ике елда нәшер ителгән монографияне чагыштырып тикшергәндә, шактый күп сораулар туа. Мәсәлән, 1941 елда чыккан нәшердә «Такташның җыентыкларының берсенә дә кертелмәгәнгә күрә» тулысынча бирелгән «Төркстан сахраларында» шигыренең 1952 елдагысында әсәрнең ике строфасы гына тәкъдим ителә [14, б. 18]. Шагыйрь, мәгълүм булганча, гомеренең Бохара чорында төбәкнең әдәби-мәдәни һәм милли тормышында актив катнаша һәм «Олуг Төркстан» газетасында чыгышлар да ясый. Шул материалларның берсендә мәүледеннәби шәрәфенә[1] мөхтәрият кичәсе үткәрелү, кичәдән кергән акчалар турында да хәбәр ителә. 1952 елгы вариантта акчалата аерым ярдәм күрсәткән Мифтахетдин һәм Низаметдин Арслановлар, Галимҗан Акчурин кебек төбәк иганәчеләренең исем, фамилияләре төшереп калдырыла [14, б. 31–32]. 1941 елдагы нәшернең 44–45 битләрдәге М. Маминның

[1] Мәүледеннәби шәрәфенә. - Мөхәммәд с.г.в.туган көне хөрмәтенә үткәрелгән кичә.

романтизм һәм аның төрләре турында чор рухындагы нәзари карашлары тулаем алынган. «Һ. Такташ поэзиясенең үзенчәлекләре» дигән бүлектә бу күренешләр тагын да арта. М. Маминның Һ. Такташ иҗатын тикшерү концепциясе сакланган хәлдә, 1952 елдагы басманың бу кисәге камилләштерелгән. Без аны шартлы рәвештә өченче бүлек дип атадык. 1941 елдагы нәшердә булмаган яңа бүлекчәләр өстәлгән, тулыландырылган. Күренә ки, икенче басманы әзерләүчеләр «текстларны бирүдә автор ихтыяры белән санлашу принцибын» сакламаганнар [15, б. 30]. Таблицага күз ташлаганда, үзгәрешләр тагын да ачыклана төшә:

| «Һ. Такташ поэзиясе» (1941) | «Һади Такташ поэзиясе» (1952) |
|---|---|
| **Беренче бүлек**. Һ. Такташның биографиясе<br>**Икенче бүлек**. Беренче эзләнүләр<br>Романтизмнан реализмга таба<br>Ныклы адымнар белән реализм юлыннан<br>Поэтик югарылык өчен алга омтылу еллары<br>Такташ иҗатында семья һәм мәхәббәт мәсьәләсе<br>Һ. Такташ поэзиясендә совет патриотизмы<br>**Өченче бүлек**<br>Һ. Такташ иҗатында композиция<br>Һ. Такташ иҗатында сурәт һәм сурәтлелек мәсьәләсе<br>Һ. Такташ поэзиясендә пейзаж<br>Такташ – поэзия мастеры | **Беренче бүлек**. Һ. Такташның биографиясе<br>**Икенче бүлек**. Һ.Такташның иҗат юлы<br>Беренче эзләнүләр<br>Реализмга таба борылышта беренче тәҗрибәләр<br>Ныклы адымнар белән реализм юлыннан<br>Поэтик югарылык өчен батыр адымнар белән алга таба омтылу еллары<br>Һ. Такташ иҗатында семья һәм мәхәббәт мәсьәләсе<br>Һ. Такташ поэзиясендә совет патриотизмы<br>**Өченче бүлек**. Һ. Такташ поэзиясенең үзенчәлекләре.<br>Һ. Такташ иҗатында композиция<br>Һ. Такташ иҗатында сурәт һәм сурәтлелек мәсьәләсе<br>Һ. Такташ поэзиясендә пейзаж<br>Һ. Такташның поэтик эш алымнары<br>Һ. Такташның иҗат эшендә поэтик процесс<br>Поэтик тел өстендә эшләү алымнары<br>Һ. Такташ поэзиясендә поэтик тел үзенчәлекләре |

Кызганычка каршы, чыганаклар, архив материаллары ачыкланмаган. Күрәсең, галимнең яңа кульязмалары табылган, яисә алар газета-журнал битләрендә аерым мәкалә рәвешендә басылгандыр, дип фаразларга гына кала. Шушыларны искә алып, мәкаләне язганда, нигездә, М. Маминның 1952 елда нәшер ителгән «Һади Такташ поэзиясе» дигән монографиясенә таянылды [14]. Шул ук вакытта чор гыйльми-нәзари фикеренә хас булып та, икенче китапны чыгаручылар тарафыннан төшереп калдырылган әһәмиятле фактларны ассызыклау, чор картинасын торгызу максаты белән, 1941 елгы вариантка да мөрәҗәгать ителде. «Һади Такташ поэзиясе» хезмәтенең структурасына килгәндә, аны өч бүлеккә бүләргә мөмкин. Беренче бүлек – «Һ. Такташның биографиясе», үз эченә алты бүлекчәне алган «Һ. Такташның иҗат юлы» дип аталган икенче бүлек һәм «Һ. Такташ поэзиясенең үзенчәлекләре» дип исемләнгән өченче бүлек. Соңгы бүлек үз эченә җиде бүлекчәне ала.

Монографияне, алда әйтелгәнчә, «Һ. Такташның биографиясе» дигән бүлек ачып җибәрә. Биредә Һ. Такташның бай, әмма кыска гомеренең баскычлары, тормышының чорлары, аны шагыйрь һәм киңкырлы шәхес итеп формалаштырган социаль, иҗтимагый һәм мәдәни шартлар бәян ителә. М. Мамин күзәтүләрендә Һ. Такташ тормышы ике чорга бүленә.

1 чор. Сыркыды – Төркстан (Бохара) – Сыркыды – Оренбург – Ташкент – Казан; 2 чор. Казан чоры. Беренче чорның һәр баскычында Такташ тормышындагы әһәмиятле вакыйгалар, аларның яшь шагыйрьгә йогынтысы, иҗат ителгән әсәрләре, аларның язылу тарихы, иҗтимагый-сәяси һәм әдәби-эстетик карашларының үзгәреше кебек мәсьәләләр бәян ителә. Шагыйрьлек сәләте ачылуга җор сүзле, телгә бай, үзендә поэзия чаткылары да булган әнисе Шәмсенисаның һәм мәктәп-мәдрәсәләрнең тәэсире, әдәбият белән туктаусыз танышып бару, рус әдәбияты һәм дөнья әдәбияты классикларының иҗатлары белән кызыксыну, төбәкләрнең мәдәни хәятында актив катнашу һ. б. лар аерып чыгарыла. Һ. Такташның иҗтимагый аңы үсешен ачыклауда М. Мамин карашларында чор идеологиясенең йогынтысы көчле. Яшь галим 1930 елларда догмага әверелгән И.В. Сталинның сәяси формулаларына, хезмәтләренә еш мөрәҗәгать итә. «Үзенең практик эше белән чыныкмаган, теоретик белеме белән дә Такташ ул елларда

пролетариат революциясенең алга куйган бурычларын большевистик аңлау дәрәҗәсенә әле җитмәгән була» [14, б. 10], – дип яза ул. М. Мамин карашынча, Һ. Такташның революцион аң ягыннан түбән булуы аның тирә-як чолганышы һәм тормыш практикасы белән дә бәйле. Бер сәбәп төсендә ул Такташның вак буржуа интеллигенциясе белән катнашуын күрсәтә [5, б. 12]. Казанга кайткач, яңа дуслар табу, җәмәгать эшләрендә катнашу, производстводагы эшчеләр белән бәйләнешкә керү, аларның эшләрен, тормышларын өйрәнү, Кызыл Армия тормышы белән танышу Такташның иҗтимагый карашларын үзгәртә.

М. Мамин Такташның сәнгатьчә фикерләвендәге үзгәрешләрне дә шагыйрьнең иҗтимагый аңы үсеше йогынтысында карый. Сыркыды авылында «Күктә сөрелгәннәр», «Үтерелгән пәйгамбәр», Ташкентта чагында «Таң кызы», «Онытылган ант», «Урман кызы», «Нәләт», «Җир уллары трагедиясе» кебек романтик рухта әсәрләр язган Такташ, Казанга килгәч, «киң күләмдә җәмәгать эшләренә катнашып китүе, пролетариат белән якынлашуы аңарда ышаныч тудыру нәтиҗәсендә, үзенең әсәрләрен реалистик нигездә яза башлый. “Гасырлар һәм минутлар”, “Сыркыды авылы”, “Давылдан соң” һәм башка әсәрләрен бер-бер артлы биреп бара» [5, б. 18–19].

Монографиянең икенче бүлегендәге «Беренче эзләнүләр» бүлекчәсе татар әдәбият белеме ирешкән казанышлар ноктасыннан Европа-Рус әдәбиятлары традицияләре белән тыгыз бәйләнештә, чагыштырма-тарихи планда эшләнгән. Ул теоретик планда язылган. Әүвәл М. Мамин аерым материалларны өйрәнеп, шагыйрьнең «Караңгы төннәрдә», «Газраилләр» әсәрләренә караганда, 1918 елда Ташкентта чыга торган «Олуг Төркстан» газетасында басылган «Төркстан сахраларында» шигырен шагыйрьнең беренче тәҗрибәсе дип билгели. Хезмәт авторы әсәрне шул вакытта хөкем сөргән идеологик ориетирлар йогынтысында анализлый. Үз фикерен тагын да дәлилләү өчен, галим, Такташның 1929 елда басылган «Таң җиле» романына мөрәҗәгать итә. Прототибы Такташ булган Рөстәмне Леонид Андреев тарафыннан иҗат ителгән вак буржуа тибындагы анархист – бунтарь Савва белән чагыштыра. Савваның искелеккә каршы көчле протест күрсәтүе Рөстәмнең дикъкатен җәлеп итә дигән караштa тора. «Шулай итеп, ул чорда Такташ иҗатындагы характерлы ике моментны дифференцияләштереп, конкрет карарга кирәк, – дип яза М. Мамин. – Бу, беренчедән, Такташның ул вакытта дөньяга карашы, икенчедән, Такташның поэтик методы. Бу ике момент берсе икенчесеннән аерылмаслык рәвештә бәйләнгән» [5, б. 39].

М. Мамин Такташның беренче чор иҗатындагы гыйсьянчылыкны, империалистик сугышка, изүчеләргә каршы юнәлдерелгән индивидуаль бунтны, кискен протестны әдәби тәэсирләр белән бәйләнештә карый һәм иң зур йогынты ясаучыларның берсе Байрон була, дигән караштa тора. «Җир уллары трагедиясе»н Байронның «Каин» әсәренә ияреп язуын әйтә. Шул ук көчле пафос һәм художество алымнарын Тукай һәм Сәгыйть Рәмиевләрдән өйрәнүен билгели [5, б. 40].

М. Мамин, Такташның «Газраилләр», «Күктән сөрелгәннәр» шигырьләренә анализ нигезендә, үз нәзари карашларын тагын да тирәнәйтә. Әсәрләрдәге чиктән тыш күпертелгән, көчле гиперболизм белән сугарылган образлылыкка нигезләнеп, Такташ поэтикасына романтизм, «романтизмга үзенең кайбер яклары белән белән якын торган символизм агымы»ның йогынты ясавын дәлилли. Бу уңайдан әдәбият галиме, профессор Г. Сәгъдинең «Символизм турында» (1932) хезмәтенә мөрәҗәгать итә. Анда Г. Сәгъди «Такташны октябрьдән соңгы татар әдәбиятына символизм агымын кертүче һәм идеологик яктан мәктәп итеп танытучы итеп куя» [5, б. 43]. Татар совет әдәбиятының бердәнбер иҗат методы итеп социалистик реализм танылып, модернистик агымнарга үтә тискәре караш яшәгән чорда М. Мамин бу фикерне кире кага.

Монография авторы Такташ каләменә символизм агымының бераз йогынтысы барлыгын таныган хәлдә, анын беренче чор иҗатын романтик чор буларак бәяли: «Такташ иҗатының беренче чорында әдәби стильләрдән символизм түгел, бәлки романтизм иң характерлы урынны алып тора. Бу агым Такташ иҗатын Байрон традицияләре астында килеп керә, һәм бу анын күпчелек әсәрләрендә чагыла» [5, б. 44]. М. Мамин, остазы Г. Нигъмәти фәнни мәктәбенең нәзари карашларына таянып, романтизмның революцион романтизм, реакцион романтизм, прогрессив романтизм канатларын аерып чыгара. Аларның хосусиятләрен билгели, татар әдәбиятыннан аерым үрнәкләр китерә. Беренче

әсәрләрендә үк кешенең хәрәкәтчел көчен, героик активлыгын раслаган, кешелек бәхетен, ирекне яклап чыккан Такташның прогрессив романтизмы революцион романтизмга әверелә дигән нәтиҗә ясый [5, б. 48]. Үз фикерен «Үтерелгән пәйгамбәр» әсәренең лирик герое, «Җир уллары трагедиясе»ндә Кабил, Идея образларының эш-гамәлләре, теләк-омтылышлары мисалында раслый. М. Мамин җентекле күзәтүләрдән соң, Һ. Такташ иҗатының романтик чорын, беренче чиратта, фәлсәфи лирика, «ул еллардагы поэзиядә иң көчле, иң художестволы лирика булып тора» дигән гомумиләштерү ясый [5, б. 60].

«Реализмга таба борылышта беренче тәҗрибәләр», «Ныклы адымнар белән реализм юлыннан», «Поэтик югарылык өчен батыр адымнар белән алга таба омтылу еллары» бүлекчәләре Һ. Такташ каләменең реализм юлыннан үсешен раслауга юнәлтелгәннәр. 1923 елда Такташ иҗатында конкретлыкка таба борылыш шагыйрьнең «Гыйсъян», «Тилеләр» әсәрләре мисалында күрсәтелә. Буржуа элементларына угын юнәлткән шагыйрь лирикасында реаль тормыш күренешләренең урын алуы ассызыклана. Реализм юлына басуының иң югары ноктасы төсендә «Эшлиләр» шигыре китерелә: «Эшлиләр» исемле шигыреннән башлап, Такташ ышанычлы адымнар белән реализм юлына баса. Ул монда пролетариатның яңа дөнья тудыручы бердәнбер көч булуын, аның бөтен киртәләрен җимереп, халык өчен рәхәт тормышка юл салуын шактый ачык гәүдәләндерә», – дип яза М. Мамин [14, б. 34–35]. «Нота», «Гасырлар һәм минутлар», «Сыркыды авылы» әсәрләре белән бу фикер ныгытыла. Чор тәнкыйтендә тискәре бәя алган «Нәни разбойник», «Әйдә энем» һәм башка әсәрләрендәге юмор элементлары М. Мамин тарафыннан шагыйрьнең поэтик югарылыкка омтылышына нисбәтле шәрехләнә.

Без шартлыча икенче бүлек дип атаган өлешнең алдагы ике бүлекчәсе («Һ. Такташ иҗатында семья һәм мәхәббәт мәсьәләсе», «Һ. Такташ поэзиясендә совет патриотизмы») Һ. Такташ рухи мирасында мотивлар төрлелеген раслау юнәлешендә язылган. «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасында, «Югалган матурлык» пьесасында галим Һ. Такташның яңа чынбарлыкта хатын-кызның урыны, иҗтимагый вазифасы, гаилә, совет җәмгыятендә ир-ат һәм хатын кыз тигезлеге, бала һәм ата-ана кебек актуаль проблемалар тирәсендә уйлануларын һәм карашларын анализлый.

Галим «Нота» шигыренә нисбәтле, илне чит дошманнардан саклау, илне, халыкны сөю, ил өчен көрәшү мотивларының Такташ иҗатын иң югары дәрәҗәгә күтәрүен әйтә. «Татар совет әдәбиятында социалистик реализмның матур чагылыш үрнәге булып кабул ителгән» «Киләчәккә хатлар» поэмасы социалистик җәмгыятьнең яңа кешесен социалистик рухта тәрбияләү, кеше аңындагы психологик үзгәрешләр аспектында анализлана. Шушы күзәтүләргә нигезләнеп, чор идеологиясенә ияреп, Такташ бөеклегендә партиянең роле берьяклы зурайтылса да, «Такташ социалистик эпоханың алдынгы шагыйре булып җитеште» дигән нәтиҗәсе белән М. Мамин хаклы иде [14, б. 63].

Өченче бүлек «Такташ поэзиясенең үзенчәлекләре» дип аталып, ул Такташның поэтик эш алымнарын һәм художество осталыгын тикшерүгә багышланган. 1941 елгы басманың бу өлеше 4 бүлекчәдән торса, икенче басмадагы өченче бүлекнең композициясе үзгәртелеп, яңалары өстәлеп, бүлекчәләр саны җидегә җиткерелә. Өченче кисәк кесә форматында басылган (10х14) 1941 елгы нәшернең 57 битен тәшкил итсә, зурайтылган форматта дөнья күргән (14х21) 1951 елгысында ул 68 битне алып тора. Аны 1941 елгы басмада булмаган уңышлы башлам ачып җибәрә.

М. Мамин бу бүлеккә нигез итеп, Такташның «Иҗат хатлары»ндагы карашларын ала. «Һәрбер язучының теге яки бу идеяне формалаштыруда аның субъектив аерымлыклары шиксез зур роль уйный. Аның психологик аерымлыклары теге яки бу идеяне формалаштыруда бик күп үзенчәлекләрен катнаштыра. Һәр язучының үзенә характерлы иҗат буяулары, конкрет бер идеяне җанландыруга кирәк булган материалны сайлый һәм аларны урнаштыра белүе бик нык үзенчә булуы мөмкин. Бу һәрбер язучының специфик моментларына бәйләнгән» [14, б. 64]. М. Мамин Такташның материалны сайлавы, урнаштыра белүе һәм шулай ук бизәкләве ягыннан үзенә бер сукмак салып, шул сукмакны киңәйткән иҗат кешесе булуын билгели.

Әдәби әсәрне язу процессы, Такташның иҗат лабораториясе 1952 елда чыккан монографиянең «Һ. Такташның поэтик эш алымнары», «Такташның иҗат эшендә поэтик процесс», «Поэтик тел өстендә эшләү

алымнары» дигән яңа бүлекчәләрендә бәян ителә. М. Мамин Такташның язучылык эшенә гаять дәрәҗәдә җаваплы каравын, үзе тикшергән, үз күзе белән күргән әйбер, вакыйга турында гына язу, тормышны тирәнтен өйрәнү аның иҗат кредосы булуын яза.

«Һ. Такташ иҗатында композиция», «Һ. Такташ иҗатында сурәт һәм сурәтлелек мәсьәләсе» бүлекчәләрендә шагыйрь поэзиясендә структура, форма проблемаларына игътибар юнәлтелә. Әлеге мәсьәлә уңаеннан, форманы өйрәнүдәге тайпылышларга кыскача бәя бирелә. Формалистларның сүзнең тышкы ягы белән кызыксынып, эчтәлекне инкарь итүләре, вульгар социологистларның поэзиянең спецификасын икенче планга калдырып, эчтәлекне төрле схемаларга сыйдырырга тырышулары, «футуризм, имажинизм кебек әдәби агымнарның массадан ерак торган формалары» тискәре бәяләнә. Такташның исә «форманы тышкы як дип кенә карамыйча, бәлки эчтәлекне реальләштерүче, идеяне укучыга җиткерүче калып, идея белән укучыны берләштерүче җеп дип карап» [14, б. 65], шигырьнең формасына зур әһәмият бирүе, ләкин форманы эчтәлектән бервакытта да аермавы шәрехләнә. Дөрес, Һ. Такташның үсеше, сәнгатьчә фикерләвенең үзгәреше, новаторлыгы социалистик төзелеш мәнфәгатьләре ноктасыннан бәяләнә: «Такташның совет татар поэзиясенә керткән яңалыгы социалистик эпоханың таләпләренә җавап бирерлек яңа эчтәлекле һәм яңа формалы шигырь тудыру өстендә эшләвеннән гыйбарәт» [14, б. 66].

Такташ иҗатындагы сурәтләрнең, тасвирларның үзенчәлекләре тикшерелә. Лирикада сурәтлелек мәсьәләсен хәл иткән Г. Тукайны Такташның алмаштыруы ассызыклана. Такташ иҗатының беренче чор лирик герое – «дөньяда дөреслекне эзләүче, кануннарга, илаһи көчләргә, патшаларга каршы, тигезлек өчен көрәшүче, бернинди читенлекләргә карамастан, хәтта тормышын да кызганмыйча, үзенең идеясен ала сөрүче сурәт» [14, б. 69]. Кеше характерына гына түгел, табигать сурәтләре дә, әйбер сурәтләре дә, ситуацияләр дә җитди төстә бирелү Такташның беренче чор лирик героеның үзенчәлекле ягы буларак ассызыклана. Такташ формалашу дәрәҗәсенә җиткәч, поэтик яктан камил, иҗат икән сурәтләре уңышлы оригиналь әсәрләр иҗат итүе билгеләнә. М. Мамин, эчтәлек белән форма арасындагы диалектик бәйләнешкә нигезләнеп, шагыйрьнең үзе билгеләгән максатына, идеясенә ярашлы художество калыбы сайлавын, чиксез күп художество чараларын күз алдында тотуын хәбәр итә. Шагыйрь каләменең абстракт сурәтлелектән конкрет, реаль образлылыкка хәрәкәт итүе хакында нәтиҗә ясала.

Табигать тасвирларының, шагыйрь рухи мирасында коры табигый күренеш итеп кенә бирелмичә, «иҗтимагый вакыйгаларны ачыклаучы декорация», вакыйганың урынын, шартларын гәүдәләндергән композицион элемент, әсәрдә тасвирлаган тормыш күренешенә контраст төсендә кулланылу үзенчәлекләре «Һ. Такташ поэзиясендә пейзаж» бүлекчәсендә бәян ителә.

Такташның язучылык һөнәренә җаваплы карашы, укучысына тирән ихтирамы аның үз әсәрләре өстендә эш стилендә дә ачык чагыла. «Такташ бер вакытта да язган шигыренең беренче вариантын матбугатка чыгармаган, ул аны берничә вариант итеп язган һәм һәрбер вариантын төзәтеп барган, яңалыклар керткән, шулай итеп, һәр шигыренең художество ягын һәм эчтәлеген сәнгатьчә эшләүдә иң яхшы үрнәкләрне биргән» [14, 90 б.]. «Мәхәббәт тәүбәсе», «Киләчәккә хатлар» поэмалары өстендә катлаулы эш процессы, архив материалларына таянып, укучы күз алдына бик җентекле китереп бастырыла. «Шулай итеп, шагыйрь үзенең шигырен («Киләчәккә хатлар» – асс. минеке) төрле вариантларда язып, очраклы моментларны төшерә бара, тормыштагы иң характерлы, иң типик вакыйгаларны сайлый, бер үк вакытта сүзләрнең иң ачык, иң эмоциональ булганнарын, иң төгәл мәгънә биргәннәрен калдыра» [14, б. 99]. Кызганычка каршы, хезмәттә чыганаклар бер урында да күрсәтелмәгән.

«Һ. Такташ поэзиясендә поэтик тел үзенчәлекләре» бүлекчәсендә шигырьдә телнең файдалану үзенчәлекләреннән темп, интонация һәм сөйләм стиле ассызыклана, алар белән параллель рәвештә шагыйрь лирикасының сүз составы, поэтик бизәк-нәкышьләр бәяләнеп бара. М. Мамин дедукция методы ярдәмендә түбәндәге гомумиләштерүне ясый: «Шигырь өлкәсендә Такташ татар совет поэзиянең новаторы булып мәйданга чыкты, һәм, ачык әйтергә кирәк, яңа поэзиянең бренче сукмагын салып кына калмады, бәлки аны киңәйтте дә. Такташ татар совет шигыре өлкәсендә яңа поэтика тудырды» [14, б. 101]. Һәм алга таба

күзәтүләр аша әлеге фикер эзлекле раслана. Дөрес, бу бүлекчәдә дә Такташ поэтикасының камилләшүе «Бөек Октябрь революциясе тарафыннан табигый рәвештә көн тәртибенә куелу» белән сәбәпле бәйләнештә шәрехләнә [14, б. 101].

Шагыйрь иске шигырь төзелешен җимереп, «табигый сөйләү юлы»н яклый. Ә бу алымның, үз нәүбәтендә, Такташка шигырьнең эчке мәгънәсен көчәйтү мөмкинлеге бирүе әйтелә. Эмоциональлек шагыйрь поэтик теленең иң характерлы ягы буларак ассызыкланып, шагыйрьнең моңа интонация, тавыш, басым ясау, хәрәкәт, ишарә стилистик фигуралары ярдәмендә ирешүе билгеләнә. Шунысы игътибарга лаек: шагыйрь поэтик телендәге һәр сурәтләү чарасы аның рухи мирасыннан бай мисаллар белән дәлилләнә. Мөрәҗәгать итү, риторик өндәү, риторик сорау, эллипсис, кабатлаулар, метафора һәм башка әдәби алымнар Такташның поэтик синтаксисында үзәк моментлар төсендә бәяләнә. 1941 елгы хезмәттә 23 битне алып торган «Такташ – поэзия мастеры» дигән бүлекчә бик нык кыскартылган, дөресрәге, аның аерым фрагментлары гына алынган.

М. Мамин шагыйрь рухи мирасының поэтик үзенчәлекләрен этрафлы тикшергәннән соң, аның поэзиясенең бер мәктәп булып торуы хакында нәтиҗә ясый: «Әнә шушы югары сыйфатлар җыелмасы һәм шул сыйфатларның үзенчәлекләре Такташ иҗатында бер мәктәп төзиләр. Аның поэтик юнәлешен мәктәп дип әйтәбез, чөнки ул чыннан да мәктәп төсен алды» [5, б. 168]. М. Мамин Такташның, үз өстендә эшләү белән генә чикләнмичә, яшь язучыларны үстерүгә зур өлеш кертүен ассызыклый. Ш. Маннур, Н. Баяннар аның поэтик мәктәбе вәкилләре буларак күрсәтеләләр.

Димәк, М. Мамин Такташ турындагы фәннең беренче сукмакларын салучы. Татар әдәбиятының классик шагыйре, новатор шагыйрь Һ. Такташ хакында язылган беренче монографиянең авторы. Татар әдәбият фәнендә шагыйрь иҗатын һәм тормыш юлын тикшереп, диссертацион һәм монографик хезмәтләр язган галимнәр буынында М. Маминның үз урыны бар. Әмма 1941 елда нәшер ителгән монография белән 1952 елдагы басманың структурасы, эчтәлеге арасында шактый аерма бар. Кызганычка каршы, камилләштерелгән, яңартылган өлешләренең чыганаклары күрсәтелмәгән. Икенче басманы кабаттан нәшер итүчеләр аерым очракларда «автор ихтыярын санлау принцибы»н сакламаганнар. 1930 елларда шулай ук Г. Нигъмәтинең аспиранты булган З. Искужинның да Һ. Такташ хакында монография язуы билгеле. Ул хезмәтнең язмышы ачыкланып бетмәгән. Бер мәкаләдә бөтен сорауларга җавап биреп бетерү мөмкин түгел. Димәк, бу юнәлештә киләчәктә тикшеренүләр, эзләнүләр алып бару соралып тора.

**Әдәбият**


1. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек: 2 томда: 2 т. / Төз.: Даутов Р. Н., Рахмани Р. Ф. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 735 б.
2. Алар сафта: Бөек Ватан сугышында һәлак булган татар совет язучыларының әсәрләре / Төз. С. Шакир. Казан: Татар. кит. нәшр., 1961. 259 б.
3. Алар сафта: Шигырьләр, хикәяләр / Төз. С. Шакир. Икенче басма. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 216 б.
4. Каһарман каләме: шигырьләр, хикәяләр, әсәрләрдән өзекләр / Төз.: В. Нуриев, Л. Сафиуллина; кереш сүз авт. И. Ибраһимов. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. 223 б.
5. *Мамин М.* Такташ поэзиясе. Казан: Татгосиздат, 1941. 172 б.
6. *Халитов Г.М.* Поэзия дерзаний. Исследование. Казань:Тат. кн. изд-во, 1980. 160 с.
7. *Гали Г.* Шагыйрь Һади Такташ турында // Сайланма әсәрләр: Хикәяләр, очерклар, тәнкыйть мәкаләләре һәм публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. 226–269 б.
8. Галимҗан Нигъмәти: тормышы, язмышы, фәнни-методик эшчәнлеге Казан: Бриг, 2018. 251 б.
9. *Салматова Г.Д.* 1920–1950 еллар иҗтимагый һәм мәдәни контекстында Шәехзадә Бабич мирасы // Tatarica. 2021. №16 (1). 78–102 б.
10. *Хәбетдинова М.* Татар әдәбият белемендә Зыя Искуж исеме // Мәдәни җомга. 2021. №1. 14–15 б.
11. *Әбүс.* Язмалар / Төз. И.К. Янбаев. Уфа: Китап, 2007. 39–41 б. (Башкорт тел.)
12. *Вәзиева Җ.* Зур галим, эшлекле остаз // Соц. Татарстан. 1987. 26 июнь.
13. Госман Х. Онытылмас остазыбыз // Казан утлары. 1997. №7. 169 – 172 б.
14. *Мамин М.* Һади Такташ поэзиясе. Казан: Татгосиздат, 1952. 123 б.
15. *Юзиев Н.* Әдәбият чыганаклары белеме (Әдәби мирасны җыйнауның, өйрәнүнең теоретик һәм гамәли мәсьәләләре). Казан: Фикер, 1998. 175 б.